КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 749

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2017 ел, 7 август, 562 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 13 июнь, 490 нчы карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның өченче абзацын төшереп калдырырга;

6 нчы пунктның таблицасында:

2 нче пунктчада «ТР Социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «РМЯҮ бүлекләре» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктчада «ТР Социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «РМЯҮ бүлекләре» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктчада «ТР Социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «РМЯҮ бүлекләре» сүзләренә алыштырырга»;

24 нче пунктчада «ТР Социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «РМЯҮ бүлекләре» сүзләренә алыштырырга»;

25 нче пунктчада «ТР Социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин